Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Тоба торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2023 елның 30 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 30 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Тоба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыннардан тыш; күрсәтелгән сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар түлиләр, 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү системаларын төзү(килешү буенча эшләр сатып алу, ташу, түләү, шул исәптән янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру);
- халыкның күпләп ял итү урынын төзү (материаллар сатып алу)

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 161җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 83 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 79 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәянителгәннәрдәнчыгып, гражданнарҗыеныкарарбирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авылҗирлегесоставынакерүче Тоба торакпунктындагражданнарҗыенынбулгандип, гражданнарҗыенынәтиҗәләрендөресдиптанырга.

2.Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Тоба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш,

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыннардан тыш; күрсәтелгән сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар түлиләр, 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәлитүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү системаларын төзү(килешү буенча эшләр сатып алу, ташу, түләү, шул исәптән янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру);
- халыкның күпләп ял итү урынын төзү (материаллар сатып алу)

«ӘЙЕ» «ЮК»

Мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Гражданнар җыенынәтиҗәләренмәгълуматстендларына, Каенлы авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарипов

«Совет «Каенлинского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»